РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ
«ГОРОД ЧИСТОПОЛЬ»
ЧИСТОПОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

**ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ЧИСТАЙ ШӘҺӘРЕ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ

**ЧИСТАЙ
ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ**

---

***Решение*** ***Карар***

**2022 елның 15 декабре** **Чистай шәһәре** **№18/2**

2023 елга һәм 2024-2025 еллар
план чорына Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районының
«Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге
бюджеты турында

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы җитәкчесе Карманова Наталья Анфиногентовнаның «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлегенең 2023 елга һәм 2024-2025 еллар план чорына бюджеты турында» докладын тыңлап фикер алышканнан соң, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Чистай шәһәр Советы

**КАРАР БИРӘ:**

1 статья

1. 2023 елга Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджетының төп характеристикаларын түбәндәгечә расларга:

1) Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләмен 191430,4 мең сум күләмендә;

2) Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджеты чыгымнарының гомуми күләме 191430,4 мең сум күләмендә.

3) Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджеты кытлыгы нульгә тигез.

2. 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджетының төп характеристикаларын түбәндәгечә расларга:

1) Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләмен 198454,9 мең сум һәм 2025 елга 206694,1 мең сум күләмендә;

2) Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджеты чыгымнарының гомуми күләме - 2024 елга 198454,9 мең сум, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнар - 4961,4 мең сум, һәм 2025 елга 206694,1 мең сум, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнар 10334,7 мең сум күләмендә.

3) Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджеты кытлыгы:

- 2024 елга тигез нульгә;
- 2025 елга нульгә тигез.

3. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларын билгеләргә

- 2023 елга әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә;
- 2024 һәм 2025 еллар план чорына әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә.

2 статья

1. Муниципаль эчке бурычның югары чиге, шул исәптән Россия Федерациясе валютасында муниципаль гарантияләр буенча бурычның югары чиге, 2024 елның 1 гыйнварына торышы буенча нульгә тигез дип билгеләргә.

2. Муниципаль эчке бурычның югары чиге, шул исәптән Россия Федерациясе валютасында муниципаль гарантияләр буенча бурычның югары чиге, 2025 елның 1 гыйнварына торышы буенча нульгә тигез дип билгеләргә.

3. Муниципаль эчке бурычның югары чиге, шул исәптән Россия Федерациясе валютасында муниципаль гарантияләр буенча бурычның югары чиге, 2026 елның 1 гыйнварына торышы буенча нульгә тигез дип билгеләргә.

3 статья

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджетында 2023 елга, әлеге карарга 3 нче кушымта нигезендә, 2024 һәм 2025 еллар план чорына керемнәрнең фаразлана торган күләмнәрен әлеге карарга 4 нче кушымта нигезендә исәпкә алырга.

4 статья

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджеты чыгымнарының ведомство структурасын түбәндәгечә расларга:

- 2023 елга әлеге карарга 5 нче кушымта нигезендә;

- 2024 һәм 2025 еллар план чорына әлеге карарга 6 нчы кушымта нигезендә.

2. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджетының бюджет ассигнованиеләрен түбәндәге бүлекләр, бүлекчәләр, максатчан статьялар (муниципаль программалар һәм эшчәнлекнең программага карамаган юнәлешләре), чыгымнарны классификацияләү төрләре төркемнәре буенча бүлүне расларга:

- 2023 елга әлеге карарга 7 нче кушымта нигезендә;

- 2024 һәм 2025 еллар план чорына әлеге карарга 8 нче кушымта нигезендә.

3.Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджеты акчалары исәбеннән 2023 елда һәм 2024-2025 еллардагы план чорына гавами йөкләмәләр үтәлми дип билгеләргә. Аларны башкару өчен акча күләме 9 нчы кушымта нигезендә нульгә тигез.

5 статья

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджетында исәпкә алу Чистай муниципаль районы бюджетыннан алына торган бюджетара трансфертлар:

-2023 елда әлеге карарга 10 нчы кушымта нигезендә 5572,5 мең сум күләмендә;

-2024 елда 3656,9 мең сум һәм 2025 елда 3715,6 мең сум күләмендә әлеге карарга 11 нче кушымта нигезендә.

6 статья

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары, Татарстан Республикасы Законнарында һәм башка норматив-хокукый актларында, шулай ук Чистай муниципаль районы һәм Чистай шәһәре норматив-хокукый актларында каралган очраклардан тыш, 2024-2025 еллардагы планлы чорда муниципаль хезмәткәрләр һәм муниципаль казна учреждениеләре хезмәткәрләре санын арттыруга китерә торган карарлар кабул итәргә хокуксыз.

7 статья

"Сәламәтлек комбинаты" муниципаль унитар предприятиесенә алынмаган керемнәрне каплауга 1022,0 мең сум һәм (яисә) товарларны җитештерүгә (реализацияләүгә), эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә бәйле фактта тотылган чыгымнарны каплауга бүлеп бирергә.

8 статья

2023 елда Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджетына 2022 ел йомгаклары буенча салымнарны түләгәннән һәм башка мәҗбүри түләүләрне башкарганнан

соң калган муниципаль унитар предприятиеләр табышының бер өлешен кертү 2023 елның 1 июленә кадәр, чиста табышның 30 проценты күләмендә башкарыла дип билгеләргә.

9 статья

Чистай районы һәм Чистай шәһәре Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаменты территориаль бүлеге төзелгән килешүләр нигезендә Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджетын үтәү буенча аерым функцияләр башкара.

10 статья

Әлеге карар 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

11 статья

Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга.

Чистай муниципаль районы
Чистай шәһәре башлыгы Д.А. Иванов